РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА
АБДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д.1, с.Абди, 422084
тел. (факс): (84360) 5-54-16,
E-mail: Abd.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘБДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

Мәктәп ур., 1 нчы йорт, Әбде авылы, 422084
тел. (факс): (84360) 5-54-16,
E-mail: Abd.Tul@tatar.ru

ОКПО 04313173 ОГРН 1021607155855 ИНН/КПП 1619000223/161901001

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**
**№7** **«11» декабря 2020 г.**

**Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлегендә биләве коррупция куркынычлары белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12, 13.3 ст. һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Указының 4 пункты, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советының 2016 елның 22 апрелендәге №18/1 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлегендә күрсәтелү турында, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» карары, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 27 декабрендәге 545 номерлы (Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы башкарма комитетының 30.12.2015 № 632; 23.05.2016 № 497, 28.08.2018 № 562; 12.11.2018 № 716, 29.12.2018 № 884; 21.10.2019 № 586; 28.08.2020 №390 карарлары редакциясендә) карары белән расланган «2015-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы нигезендә,

1.Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлегендә биләве коррупция куркынычлары белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлеген расларга, кушымта нигезендә.

2. Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге башлыгының 2019 елның 14 ноябрендә № 2 «Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлегендә биләве коррупция куркынычлары белән бәйле булган муниципаль вазыйфалар һәм

муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» карары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта дип танырга.

3. Әлеге боерык гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның  үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Н.Р.Рахматуллин

1 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге башлыгының «11» декабрендә 2020 ел № 7 боерыгы белән расланган

# Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлегендә биләве коррупция куркынычлары белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлеге

Әбде авыл җирлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары:

1.Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:
Әбде авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;
Әбде авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе.